**МИНИСТЕРСТВО ПРОСВЕЩЕНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ**

**Министерство образования и науки Республики Татарстан**

**Исполнительный комитет Арского муниципального района**

**Республики Татарстан**

**МБОУ "Шушмабашскаясош"**

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
|---|---|---|
| Руководитель ШМО<br>________________________<br>Тазетдинова Г.Р.<br>Протокол №1 от «24» августа 2023 г. | Заместитель директора по УВР<br>________________________<br>Фатхрахманова Л.Ш.<br>. от «24» августа 2023 г. | Директор школы<br>________________________<br>Шаймарданова Р.Г.<br>Приказ №160 от «25» августа2023 г. |

**РАБОЧАЯ ПРОГРАММА**

**учебного предмета «Литературное чтение на родном (татарском) языке»**

для обучающихся 1-4 классов

**Шушмабаш 2023**

**Аңлатма язуы**

1 класс өчен әдәби укудан эш программасы түбәндәге норматив документларга нигезләнеп төзелде:

1. Россия Федерациясенең ”Мәгариф турында ” Федераль законына ( 21.12.2012. ,N273-ФЗ) (үзгәрешләр белән 21.07.2014);
2. Татарстан Республикасының “Мәгариф турында” законына (22.07.2013 №68-3 РТ);
3. Башлангыч белем бирү Федераль дәүләт белем стандартына Приказ РФ (6 октябрь, 2009 №373) ( үзгәрешләр белән);
4. Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән министрлыгы приказына 31.12 2015ел №1576 ( «О внесении изменений в федеральный государственный стандарт начального общего образования, утвержденный приказом Министерства образования и науки Российской Федерации от 6 октября 2009 г. №373»)
5. Дәүләт стандартының Федераль компонентына нигезләнгән башлангыч мәктәпләрнең татар теле фәненнән үрнәк программасына;
6. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Шушмабаш урта гомуми белем мәктәбенең башлангыч белем бирү буенча төп укыту программасы (Приказ №155 27 июнь 2015 ел);
7. Дәүләт аккредитацияле һәм гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыручы учреждениеләрнең белем бирү процессынна тәкъдим ителгән (рөхсәт ителгән) дәреслекләрнең федераль һәм региональ исемлеге; (Приказ МО и Н РФ от 31 марта 2014г. №253; Приказ МО и Н РФ от 8 июня 2015 г. № 576 «О внесении изменений в Федеральный перечень учебников, рекомендуемых к использованию при реализации имеющих государственную аккредитацию образовательных программ начального общего, основного общего, среднего общего образования, утвержденный приказом МО и Н РФ от 31 марта 2014 г. №253»)
8. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Шушмабаш урта гомуми белем мәктәбе” муниципаль бюджет белем учреждениесенең 2016-2017 нче уку елына укыту планы ( кабул ителде: приказ № 120 , 26 август 2016 ел);
9. Федераль дәүләт стандартлары таләпләренә туры килгән эш программасы турында ГБМБУ “Шушмабаш урта гомуми белем бирү мәктәбе” нигезләмәсе.

Программа үстерешле укыту принциплары белән традицион ныклы белем үзләштерү принциплары үзара тыгыз бәйләнештә торган **“Перспектив башлангыч мәктәп” концепциясенә** нигезләнеп эшләнде. Ул, татар мәктәпләрендә укытыла торган “Әдәби уку” программасының төп өлеше буларак, алга таба белем алуга нигез булып тора.

Әзерлек чоры түбәндәге **максатка** ия:

- кешеләрнең әйтеп һәм язып сөйләшүләрен гомуми күзаллау

Әлифба чоры түбәндәге **максатларга** ия:

- Сузык һәм тартык авазлар һәм аларның хәрефләре белән, сүзләрнең калын һәм нечкә әйтелешен билгеләүче калын һәм нечкә сузык аваз хәрефләре белән танышу. Сузык аваз хәрефләренә карап, сүзләрнең калын һәм нечкә әйтеп укылуын күзәтү
- Кисмә хәрефләрдән һәм кисмә кушылмалардан сүзләр төзү һәм төзелгән сүзләрне кычкырып уку
- Хәрефләрне дөрес һәм чагыштырмача тиз танып җанлы сүздәге авазлар мәгънәсендә уку

Әлифбадан соңгы чор **максатлары**:

- нәниләр өчен басылган китаплар белән таныштыру, мөстәкыйль укуга омтылыш булдыру;

- рәсемнәргә карап хикәянең эчтәлеген сөйләү;
- дәрестән тыш укыганны тыңларга гадәтләндерү

**Бурычлар:**

- укучыларда сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен үстерү һәм телне аралашу чарасы буларак барлык ситуацияләрдә кулланырга өйрәтү;
- аралашу һәм танып белү чарасы булган телне аңлы үзләштерүгә ирешү;
- балаларны текст, китап белән эш итү алымнарына йөрәтү;
- коммуникатив сөйләм осталыгы һәм иҗади сәләт арасында иҗади бәйләнеш булдыру;
- укучыларның образлы, логик фикерләүләрен үстерү, аларда аралашу культурасы күнекмәләрен тәрбияләү.

**Предметның укыту планындагы урыны**

Программа 33-34 сәгатькә нигезләнеп төзелгән. Әдәби уку фәненә базис укыту планында атнага 1 сәгать вакыт бирелә.

**Программаны үзләштерүнең көтелгән нәтиҗәләре**

Универсаль уку гамәлләре

***Танып белү универсаль уку гамәлләре:***

- дәреслектә ориентлаша белү;
- шартлы билгеләрнең телен белү;
- текстның билгеле бер өзегенә дәреслектән иллюстрацияне табу;
- тексттан билгеләнгән өзекне табу;
- материаль объектлар кулланып биремнәр үтәү;
- дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәрендәге мәгълүматлар белән эшли белү;
- дәреслек һәм хрестоматиядәге, дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәрендәге шартлы билгеләрне туры китерү.

***Регулятив универсаль уку гамәлләре:***

-кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;
- гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау;
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;
- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

***Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре:***

- дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз уңышларың/уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү;
- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау кую)

***Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:***

- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- күршең белән хезмәттәшлек итү.

**Предмет нәтиҗәләре**

- Гади җөмлә ахырындагы тыныш билгеләренә, җөмлә эчендәге тиңдәш кисәкләргә, эндәш сүзләргә туры килгән интонация һәм паузаларга игътибар итеп укый белү;
- Уку гигиенасын һәм китапны саклап тоту кагыйдәләрен үтәү;
- Китапларны эчтәлегенә карап аера белү, китап, әсәр исемнәрен дөрес әйтү;

- Текст кисәкләрен төшереп калдырмыйча, таныш әкият яки хикәя эчтәлеген укытучы сораулары буенча сөйләү;
- Картина буенча бәйләнешле сөйләм төзү;
- Укылган җөмләләргә яки текстларга карата сорауларга телдән җавап бирү.

**Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр**

**Шәхси**

укучыда татарча укуга кызыксыну, омтылыш уяту; әдәби уку тәҗрибәсе булдыру; үз милләтең белән горурлану, татар теленә мәхәббәт хисләре тәрбияләү;

**Метапредмет:**

**Коммуникатив** :

**Укучы өйрәнәчәк:** татар халык авыз иҗаты әсәрләрен, мәкаль һәм әйтемнәрне урынлы кулланырга өйрәнү; текстны аңларга, аңлаганны тыңлаучыга җиткерергә, дөрес һәм матур итеп укырга, укыганның эчтәлеген сөйләргә, тема буенча әңгәмә кора белергә, аралашканда тел чараларын урынлы файдалана белергә өйрәнү; әсәрнең темасын һәм төп геройның характерын, эш-гамәлләрен, әсәрдәге вакыйгаларга, геройларга карата үз фикерләрен белдерергә өйрәнү;

**Укучы үзләштерү мөмкинлеге алачак:** татар халык авыз иҗаты әсәрләрен, мәкаль һәм әйтемнәрне урынлы куллана белү; текстны аңлый, аңлаганны тыңлаучыга җиткерә, дөрес һәм матур итеп укый, укыганның эчтәлеген сөйли, тема буенча әңгәмә кора , аралашканда тел чараларын урынлы файдалана белү; әсәрнең темасын һәм төп геройның характерын, эш-гамәлләрен, әсәрдәге вакыйгаларга, геройларга карата үз фикерләрен әйтә белү;

**Регулятив :**

**Укучы өйрәнәчәк:** татар әдипләренең иң яхшы әдәби әсәрләре белән танышырга өйрәнү; әдәби әсәрләрне дөрес һәм йөгерек, аңлап, сәнгатьле уку күнекмәләре булдырырга өйрәнү;
татар халык авыз иҗаты әсәрләрен , мәкаль һәм әйтемнәрне урынлы кулланырга өйрәнү;

**Укучы үзләштерү мөмкинлеге алачак:** татар әдипләренең иң яхшы әдәби әсәрләрен белү; әдәби әсәрләрне дөрес һәм йөгерек, аңлап, сәнгатьле уку күнекмәләре булдыру, уку тизлеге нормаларына сыешу алу; татар халык авыз иҗаты әсәрләрен белү, мәкаль һәм әйтемнәрне урынлы куллана белү;

**Танып- белү:**

**Укучы өйрәнәчәк:** халык әкиятләрен һәм фольклор жанрларын, автор әкиятләрен, хикәя, шигырь, мәзәкләрне һ.б. әдәби жанр буларак өйрәнү ;

**Укучы үзләштерү мөмкинлеге алачак:** халык әкиятләрен һәм фольклор жанрларын, автор әкиятләрен, хикәя, шигырь, мәзәкләрне һ.б. әдәби жанр буларак кабул итә белү;

**Предмет**

**Укучы өйрәнәчәк**: катлаулы булмаган монолог төзергә өйрәнү; геройлар һәм вакыйгаларга характеристика бирергә өйрәнү; укылган әсәрнең эчтәлеген план буенча ачарга өйрәнү; шигъри әсәрләрне сәнгатьле укырга өйрәнү; иптәшләре алдында кыска чыгышлар ясарга өйрәнү; дәреслек һәм фәнни-популяр әдәбият белән эшләргә өйрәнү; алган белемнәрне практикада кулланырга өйрәнү; укытучы ярдәмендә персонажларга бәя бирергә өйрәнү; төркемнәрдә үз фикерләрен дәлилли белергә өйрәнү.

**Укучы үзләштерү мөмкинлеге алачак:** катлаулы булмаган монолог төзи белү; геройлар һәм вакыйгаларга характеристика бирү; укылган әсәрнең эчтәлеген план буенча ачу; шигъри әсәрләрне сәнгатьле укый белү; иптәшләре алдында кыска чыгышлар ясау; дәреслек һәм фәнни-популяр әдәбият белән эшләргә күнегү; алган белемнәрне практикада куллана белү; укытучы ярдәмендә персонажларга бәя бирә белү; төркемнәрдә үз фикерләрен дәлилли белү.

## Курсның эчтәлеге

**1.Әлифбагача чор (2 сәг.)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

Текст турында башлангыч күзаллау булдыру. Иллюстрация буенча җөмләләр төзү. Рәсем белән бирелгән хикәяне исемләү. Тәкъдим ителгән график моделе буенча хикәя эчтәлеген сөйләү. Укытучы укыган текст эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга җавап бирү. Телнең структур берәмлеге буларак сүз турында башлангыч күзаллау булдыру. Басма хәрефләрнең өлге элементлары белән танышу.

**2.Әлифба чоры (19 сәг.)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

Сузык авазларны аеру күнегүләре. Иҗек ясау процессында сузыкларның роле.сүз кисәге буларак иҗек турында белешмә. Сүзнең иҗекләргә бүленешен дуга ярдәмендә билгеләү. Схемада сузык авазны башта түгәрәк, ә тартыкларны квадрат, соңыннан транскрипция билгесе белән күрсәтү. Ишетелгән һәм әйтелгән сүзләр арасыннан өйрәнелә торган аваз кергән сүзне таный һәм аера белергә өйрәнү. Өлге элементы ярдәме белән басма хәрефләр төзү һәм аларның формаларын үзләштерү. Хәреф турында авазның тышкы билгесе, ягъни “киеме” буларак образлы күзаллау булдыру. Баш һәм юл басма хәреф формаларын төзү.

Табышмаклар, тизәйткечләр, санамышлар, үртәвечләр, өйрәнелә торган аваз булган халык мәкальләрен уку, истә калдыру һәм хәтер буенча сөйләү.

**3.Халык авыз иҗаты һәм әдәбият (3 сәг.)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

Халык авыз иҗаты турында гомуми кузаллау. Авторларның булмавы, телдән сөйләм, практик-уен характерындагы кече жанр әсәрләре. Бишек җырлары, санамыш, табышмак, тизәйткеч, эндәшләр. Әйләнмәле һәм чылбыр әкиятләр. Халык авыз иҗатының табышмак, әйләнмәле әкият кебек формаларын практик үзләштерү.

Сурәтләнгән вакыйгаларга карата автор фикерләре(әсәр исеме, геройларга характеристика, авторлар бәяләмәсе)

**4.Әсәрнең эмоциональ тоны(3 сәг.)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

Юмористик һәм җитди характердагы әсәрләр. Әсәрләрне телдән кычкырып, ятлап укыганда эмоциональ характерын чагылдыру.Тавыш төсмерләре- интонация, тон, тавыш көче, темп, пауза, логик басым, сүзсез мимика, хәрәкәтләр, ымнар.

**5.Әдәби сәнгатьлелек чаралары(3 сәг.)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

Текстларны анализлаганда сәнгатьлелек чараларын табарга күнектерү. Сурәтләү чаралары турында беренчел кузаллау булдыру, кабатлауларның мәгънәсенә төшенү, тавышның сәнгатьлелеген ачыклау: рифма, ритм төшенчәсе бирү.

**6.Әдәби жанрлар(3 сәг.)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

Жанрлар турында гомуми кузаллау булдыру: хикәя, шигырь. Хикәянең исеме. Ике образны чагыштырып сөйли белү. Әсәрдәге геройларга карата үз фикерен белдерү. Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып танып белү: шагыйрь матурлыкны тоя белергә өйрәтә. Рифма белән танышу: аны таба, куллана белергә күнектерү.

**Милли төбәк компоненты**: татар язучылары иҗаты , татар халык авыз иҗаты һәм татар газета-журналлары белән белән танышу.

## Предметны өйрәнү буенча планлаштырылган нәтиҗәләр

**Укучы өйрәнер:**

- шигырьләрне сәнгатьле итеп уку;
- әсәрнең мәгънәви кисәкләре арасындагы бәйләнешләрне ачыклау, төп фикерне билгеләү һәм аны үз сүзләре белән әйтеп бирү;

- кыска күләмле әсәрләрнең эчтәлеген сөйләү;
- тылсымлы һәм хайваннар турындагы әкиятләрне аера белү;
- әсәрдәге төп геройга мөнәсәбәт белдерү;
- укылган әсәрдән чагыштыру, җанландыру, контрастны таба белү;
- 2–3 татар классигының исемен;
  - үзенә иң ошаган авторның берничә әсәрен;
- китапның төрле элементларына карап эчтәлеген билгеләү;
- сүзлекләрдән кирәкле мәгълүматны табу;
- авторның үз героена мөнәсәбәтен билгеләү;
- яраткан әдәби герое турында сөйли белү;
- дәреслектә дөрес ориентлашу, китапның элементларын төгәл билгеләү, авторын, исемен, эчтәлек язылган битен табу, иллюстрацияләр белән эшли белү;

**укучы өйрәнергә мөмкинлек ала**

- мөстәкыйль рәвештә китаплар сайлый белү, китап элементлары буенча аның эчтәлеген ачыклау;
- сүзлекләр белән мөстәкыйль эшләү;
- аңлап, йөгерек уку күнекмәләре булдыру;
- текстның темасын, төп фикерен табу, текстны мәгънәви кисәкләргә бүлү, текстның планын төзү, тулы һәм кыскача эчтәлекне бирә белүләренә ирешү;
- фольклор әсәрләрен тану, автор әсәрләре белән уртаклыгын, аермасын билгеләү;
- әсәрдәге геройлар турында үз фикерләрен әйтә белүләренә ирешү, геройларның характерын ачыклау, чагыштыру;
  - дәреслектә оста ориентлашу;
- уку елында өйрәнелгән әдәби әсәрләрнең исемен, авторын, эчтәлеген;
- 1–2 балалар журналын, аның бүлекләрен;
- теге яки бу авторларның китапларын (бирелгән исемлек буенча, чыгыш әзерләү өчен) мөстәкыйль рәвештә китапханәдә сайлый белү, китап элементлары буенча аның эчтәлеген ачыклау;
- сайланган әсәрләрне мөстәкыйль уку.

**Укучы өйрәнәчәк**: катлаулы булмаган монолог төзергә өйрәнү; геройлар һәм вакыйгаларга характеристика бирергә өйрәнү; укылган әсәрнең эчтәлеген план буенча ачарга өйрәнү; шигъри әсәрләрне сәнгатьле укырга өйрәнү; иптәшләре алдында кыска чыгышлар ясарга өйрәнү; дәреслек һәм фәнни-популяр әдәбият белән эшләргә өйрәнү; алган белемнәрне практикада кулланырга өйрәнү; укытучы ярдәмендә персонажларга бәя бирергә өйрәнү; төркемнәрдә үз фикерләрен дәлилли белергә өйрәнү.

**Укучы үзләштерү мөмкинлеге алачак:** катлаулы булмаган монолог төзи белү; геройлар һәм вакыйгаларга характеристика бирү; укылган әсәрнең эчтәлеген план буенча ачу; шигъри әсәрләрне сәнгатьле укый белү; иптәшләре алдында кыска чыгышлар ясау; дәреслек һәм фәнни-популяр әдәбият белән эшләргә күнегү; алган белемнәрне практикада куллана белү; укытучы ярдәмендә персонажларга бәя бирә белү; төркемнәрдә үз фикерләрен дәлилли белү.

**Метапредмет:**

**Коммуникатив** :

**Укучы өйрәнәчәк:** татар халык авыз иҗаты әсәрләрен, мәкаль һәм әйтемнәрне урынлы кулланырга өйрәнү; текстны аңларга, аңлаганны тыңлаучыга җиткерергә, дөрес һәм матур итеп укырга, укыганның эчтәлеген сөйләргә, тема буенча әңгәмә кора белергә, аралашканда тел чараларын урынлы файдалана белергә өйрәнү; әсәрнең темасын һәм төп геройның характерын, эш-гамәлләрен, әсәрдәге вакыйгаларга, геройларга карата үз фикерләрен белдерергә өйрәнү;

**Укучы үзләштерү мөмкинлеге алачак:** татар халык авыз иҗаты әсәрләрен, мәкаль һәм әйтемнәрне урынлы куллана белү; текстны аңлый, аңлаганны тыңлаучыга җиткерә, дөрес һәм матур итеп укый, укыганның эчтәлеген сөйли, тема буенча әңгәмә кора , аралашканда тел

чараларын урынлы файдалана белү; әсәрнең темасын һәм төп геройның характерын, эш-гамәлләрен, әсәрдәге вакыйгаларга, геройларга карата үз фикерләрен әйтә белү;
**Регулятив :**
**Укучы өйрәнәчәк:** татар әдипләренең әдәби әсәрләре белән танышырга өйрәнү; әдәби әсәрләрне дөрес һәм йөгерек, аңлап, сәнгатьле уку күнекмәләре булдырырга өйрәнү; татар халык авыз иҗаты әсәрләрен , мәкаль һәм әйтемнәрне урынлы кулланырга өйрәнү;
**Укучы үзләштерү мөмкинлеге алачак:** татар әдипләренең әдәби әсәрләрен белү; әдәби әсәрләрне дөрес һәм йөгерек, аңлап, сәнгатьле уку күнекмәләре булдыру, уку тизлеге нормаларына сыешу алу; татар халык авыз иҗаты әсәрләрен белү, мәкаль һәм әйтемнәрне урынлы куллана белү;
**Танып- белү:**
**Укучы өйрәнәчәк:** халык әкиятләрен һәм фольклор жанрларын, автор әкиятләрен, хикәя, шигырь, мәзәкләрне һ.б. әдәби жанр буларак өйрәнү ;
**Укучы үзләштерү мөмкинлеге алачак:** халык әкиятләрен һәм фольклор жанрларын, автор әкиятләрен, хикәя, шигырь, мәзәкләрне һ.б. әдәби жанр буларак кабул итә белү.
**Шәхси**
укучыда татарча укуга кызыксыну, омтылыш уяту; әдәби уку тәҗрибәсе булдыру; үз милләтең белән горурлану, татар теленә мәхәббәт хисләре тәрбияләү

## Укыту предметының эчтәлеге

**Халык авыз иҗаты.**
**Мифлар турында гомуми күзаллау булдыру.**
Борынгы халыкларның тормышы, кеше һәм табигать арасындагы мөнәсәбәт. Тормыш агачы. Тотем хайван һәм үсемлекләр, кешеләрнең аларга карашы, борынгы традицияләрнең сакланышы.
**Тылсымлы әкиятләр.**
Дөнья турында борынгы күзаллаулар чагылышы. Тылсымлы әкият герое. Тылсымдөньясы. Тылсымлы предметлар, сихри саннар, сүзләр, тылсымлы булышчылар, тылсымлы әкият законнары: әкият герое өеннән чыгып китә. Максатка ирешү юлы (тылсымдөньясы, карурманнар аша үтүче юл, сынаулар, тылсымлы булышчы ярдәме, җиңү шатлыгы.) Халык әкиятләренең мифлар, легендаларда чагылышы.
**Риваять һәм легендалар.**
Риваять һәм легендаларда сөйләнгән геройлар, аларның кичерешләре. Тарихи бәйләнеш. Төрле атамалар. Аларның килеп чыгышы.Риваять һәм легендаларда бирелгән вакыйгаларның әкиятләрдә чагылышы.
**Автор әкиятләре.**
Автор әкиятләренең халык әкиятлре белән охшашлыгы (жанр һәм сюжет). Халык әкиятлрендәге тылсым юлы белән җиңүләр, автор әкиятләрендә акыл белән эш итеп уңышка ирешү, ярату һәм яратыла белүнең көче.
**Фольклор жанрының тормышта, хәзерге вакытта яшәеше.**
Халык традицияләре һәм бәйрәмнәре. Символик төшенчәләр. Гимннар (Татарстан гимны). Халык һәм автор әкиятләре.
**Хикәя.** Хикәя жанры турында күзаллау формалаштыруны дәвам итү. Хикәя геройлары, аларның портреты һәм характер үзенчәлекләренең башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте. Геройларга чагыштырмача характеристика. Герой яшәгән тирәлек, пейзаж.Хикәядәге чынбарлык чагылышы. Әдәби тел берәмлекләре.
**Әкият һәм хикәя жанрының үзгәлеге турында күзаллау формалаштыру.**
Әкият һәм хикәя жанрларының композиция үзенчәлеген (күзәтүләр аша) аңлату. Укучы-тыңлауга табигый көчләрнең серен, әкият геройларының серле тормыш агышын күрсәтү, хикәя геройлары-ның характерларында тормыштан алынган вакыйгаларны чагылдырып сөйләү.

**Шигърият.** Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөнья матурлыгын шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуын инандыру. Шагыйрьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет.
Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру,контраст,җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре:темп,тавыш көче,тон,сөйләм мелодикасы(тавышны кутәрү ,түбәнәйтү).
**Әсәр авторлары турында.**
Шагыйрь, язучы, рәссамның биографиясе.
а) әсәрдә авторлар кичереше;
ә) автор күзәтүләренең чагылыш;
б) хәзерге заман авторлары белән очрашу, балаларның авторга сораулары, җаваплар.
**Библиографик культура формалаштыру.**
Эчтәлек бите белән танышу, аңа карап, кирәкле әсәрне китаптан таба белү, кече яштәге мәктәп баласының дәреслектән тыш эчтәлген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану. Фән буенча сүзлек, белешмә әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләү. Балалар китабы белән эшләү. Китапның төп өч элементын аеру: китап тышлыгы, китап төпсәсе, битләре. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру. Төрле җыентыклар төзергә өйрәнү.
**Уку, сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру.**
Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру *( интонация, тон, темп саклап кычкырып уку)*. Автор бирергә теләгән картинаны күзал-лау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда, үз урыныңны белеп, чират буенча уку. Укылган әсәргә анализ ясау. Уку техникасын үстерү.
**Укыла торган әсәрләр**
**Халык авыз иҗаты.**
“Җир ничек яралган?” (легенда), “Күкнең күтәрелүе (хикәят), “Айдархан һәм сәхабәләр, (легенда), “Пәйгамбәрнең тууы һәм аның балачагы”, “Абага чәчәге (хикәят), “Ак бүре”(риваять), “Кырык кыз”( риваять), “Мәрҗан каласы һәм унике кыз” (хикәят), “Дөнья яратылу турында” (миф), “Хапи алла турында” (миф), “Чыршы ни өчен мәңге яшел?” (легенда) . әкиятләр: “Ак байтал”,“Ак бүре”, “Еланнар патшасы Шаһмара”, “Үги кыз” , “Ике кыз”, “Бумеранг”(Австралия халкы әкияте).
**Борынгы язучылар һәм татар әдәбияты классиклары**
Кол Гали “Кыйссаи Йосыф”.  Г. Тукай : “Таз”, “Яз галәмәтләре”. Дәрдемәнд: “Гали”. З. Ярмәки: “Иртә”, “Ак каен”. М.Җәлил: “Дару”. К.Насыйри. “Каз итен коймакка төреп,каймакка манып ашау”. Н.Исәнбәт: “ Кышкы төндә”, “Туган ил”, “Өч матур сүз”. Ш.Бабич: “ Тын төн”, “Габдулла әфәнде Тукай”. .
А. Алиш. “Сертотмас Үрдәк”. Г.Кутуй.” Яшен”. Ш.Галиев:”Кол Галигә”, “Алсу дөнья”, “Җирдә миңа ни кирәк?”, “Урман ява”, “Тукран сые”.
Г.Ибраһимов: “ Укудан кайткач”. Г.Галиев.” Бибкәй аланы”. Ф.Әмирхан. “ Кечкенә хезмәтче”. К.Нәҗми: “Нәсимәнең беренче эш көне”.
З.Бәшири: “ Бер асрауның аһ-зары”. Н.Думави: “ “Беренче кар”, “Ятим бала”. М.Мәһдиев: “Бәхилләшү”. С.Хәким: “ “Яратам мин”, “Тегермән стенасындагы язулар”. Ә.Фәйзи :”Асрарга бала бирәм”. Ф.Хөсни:”Малай белән солдат”. Ш.Рәкыйпов: “ Төнге очыш”. И.Туктар: “Букет”, “Бер каен үсә”. Г.Хәсәнов: “ Аккош”, “Абага”.Г.Сабитов: “Кадерле ул туган як!”, “Чәчәк нигә боекты?”. Н.Арсланов: “Халкыма”. Җ.Тәрҗеманов: “Шуктуган”, “Тукран малае Шуктуган”. Л.Ихсанова : “ Шомырт чәчәкләре ак кына”. Ф.Яруллин: “Буар елан”. М.Әгъләмов: “Матурлык минем белән”. Зөлфәт: “Кыз тавы”. С.Шакир: “ Ландыш чәчәге”. Р.Хафизова: “Кирлемән”. Г.Латыйп: “Минем нәсел”. Р.Гыйззәтуллин: “Язгы моң”. К.Тимбикова: “Бану әби сабагы”. К.Сибгатуллин: “Чыпчык”, “Бөтен кеше бүген шундый әйбәт”. Роб.Әхмәтҗанов: “Безнең шигырь”. Р.Хисмәтуллин: “Аһ. Бер китсә кирегә...”
**Рус язучылары:**
Л. Толстой  “Слива төше”. Н. Сладков: “Тыштан ялтырый. ‘эчтән калтырый».
**Татар язучылары һәм шагыйрьләре (бүгенге көн язучылары)**

Р. Миңнуллин: “Иртән иртүк”, “Атказанган сандугач”, “Машина тавышлы көчек турында кечкенә әкият”, “Сабантуйда”, “Татарларым”, “Минем телем”, “Утыз Имәнине укыганда туган уйлар”.
Р. Фәйзуллин: “Быелгы яз”, “Минем эти”. Х.Камалов: “ Археолог”. Ә.Рәшит: “ Нәсел агачы”. К.Булатова:”Кичә генә”, “Шушы яктан, шушы туфрактан без”. Җ.Дәрзаман: “Бөҗәкләр белән сөйләшү”. Р. Вәлиева: “Изгеләр тавы”, Энҗе чәчәк”. “Бөтен дөнья ак кына”, “Онытма!”. Р. Вәлиев: “Кошлар кайта”, “Кайтчы, Сөембикә”, “Эт кояшы” (өзек), “Ватаным”. Н. Әхмәдиев: “Хәерле иртә”. И.Гыйлаҗев: “Тутыкмас тотка”, “Охшашлык”. Р.Харис: “Татарстан әләме”, “Зөләйха”, Ак карлар арасында”, “Елмай”, “Туган җирем”, “Фронтовиклар”. Л. Лерон: “Кыхмырый, Мыхмырый һәм Шыхмырый”.
Э. Шәрифуллинаб “ Табигатьнең бер бөртеге”, Без татар балалары”, “Тормыш яме”. Г. Гыйльманов: “ Чишмәгә бардык”, Кайтаваз”, “Курай”, “Җавапсыз легенда”, “Минем исемем – Бүрек”. В. Нуриев: “Ачуланма инде. Илһам!” Г. Рәхим:”Көз йөри”, “Көзге моң”, “Көзге урман”, “Песнәк”, “Апрель”.
Р. Корбан: “Көз нинә моңлы?”, “Ярдәм итик”, “Курай”. Йолдыз: “ Очрашу”. Р.Мингалим: “ Бүген төнлә күккә кара”. Батулла: “ Суияләре”(әкият), “Терек-терек кырмыска”, “Салават күпере кайда йоклый?” В.Хәйруллина “ Хәерле көн”, “Алмаштыру”,“Наз”, “Чикерткә”. М.Мирза: “ Көз”, “Балачак хатирәсе”.
Ф.Бәйрәмова: “Кара пулат”. Мөҗәһит: “Бер яфрак зары”. Д.Гайнетдинова: “Исәнме, яңа көн”, “Батыр Хәбир”. Л.Гыймадиева: “Кара урман, караңгы төн”.
Н.Сәйяр: “ Айсылу”. Р.Рахман: “ Кесәл”. Н.Каштан: “ Әрем исе”.Г.Вәлиева: “Кызыктырсалар да”, “Карт алаша колагы”. Ф.Тарханова: “Без бәлеш пешерәбез”, “Килде пилмән ашыйсы”. И Нәбиуллина: “Тәмле тел”. Ф. Мәҗитов: “Яңгыр кызы Гөлтамчы”. Г.Мөхәммәтшин: “ Туган як”. М.Галиев: “ Туган як”. Г.Морат: “ Чит тел”. С.Гаффарова: “Көз”. Р.Зәйдулла: “Кол Гали”.

**Милли-региональ компонент**

Халкыбызның гореф-гадәтләре белән тирәнтен таныштыру. Төбәктә яшәүче язучылар, сәнгать кешеләре белән танышу. Милли бәйрәмнәрнең тарихы белән таныштыру

## Календарь-тематик планлаштыру

**УМК** “Перспективная начальная школа” Әлифба. И.Х.Мияссарова, Ф.Ш.Гарифуллина, Р.Р.Шәмсетдинова. Казан, Учебник для образовательных организаций начального общего образования с обучением на родном (татарском) языке. 1 класс “Магариф – Вакыт”, 2016.
Әдәби уку. Г. М. Сафиуллина, М.Я. Гарифуллина, Ф. Ф. Хасанова, А. Г. Мухамметзянова. Учебник для начальной общеобразовательной школы с татарским языком обучения.1 класс. Казань. Издательство “Магариф – Вакыт”.2012.

| № | Дәреснең темасы | Сәг саны | Үткәрү вакыты | | Ис-кәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | План | Факт | |
| 1 | “Өч кыз”,”Куян кызы” әкиятләре. Предметны, предметның билгесен белдерүче сүзләр. Әкият текстын тыңлау. Иллюстрацияләрнең (рәсемнәрнең) текст өлешләре белән бәйләнешен (мөнәсәбәтен) ачыклау. Әкият эчтәлеген сөйләү. Балаларда текст турында, беренчедән, мәгънә ягыннан үзара бәйләнгән һәм хәбәр итү интонациясе белән әйтелә торган, якынча тәмамланган фикерне белдерүче, билгеле бер эзлеклелектә килгән сүз һәм җөмләләр | 1 | 1.09 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | җыелмасы буларак, икенчендән, нәрсә турында да булса хәбәр итүче һәм ишетеп, күреп зиһенгә алына торган мәгълүмат буларак башлангыч күзаллау булдыру. | | | | |
| 2 | Сүз һәм аның лексик мәгънәсе. [а], [ә] авазлары. А,а; Ә,ә хәрефләре. Иллюстрация темасы буенча җөмләләр төзү. | 1 | 8.09 | | |
| 3 | Сүздәге авазларның санын һәм эзлеклелеген билгеләү. [ы] , [э], [и] авазлары. Э,э; И,и ; Ы,ы хәрефләре. | 1 | 15.09 | | |
| 4 | Аваз, иҗек, сүз, җөмлә һәм текст турында образлы күзаллау формалаштыру. [ү] ; [у] авазы. Ү,ү ; У,у хәрефләре. | 1 | 22.09 | | |
| 5 | Калын һәм нечкә сузыкларны аеру, аларны хәрефләр белән белдерү. [о] ; [ө] авазы. О,о ; Ө,ө хәрефләре. | 1 | 29.09 | | |
| 6 | Сузык һәм тартык авазлар. Тартык авазларның яңгыраулыгын белдерүче билге — уртасында нокта булган квадрат белән билгеләү. [н] авазы. Н,н хәрефләре. | 1 | 6.10 | | |
| 7 | Иҗек. Иҗек калыплары. Иҗекләп уку күнекмәләрен формалаштыру (сузык аваз хәрефләренә карап, сүзләрне калын һәм нечкә итеп уку). [л] авазы. Л, л хәрефләре. | 1 | 13.10 | | |
| 8 | Әйтелгән сүздән аерым сузык яки тартык авазны ишетеп, аерып алу. [м] авазы, М,м хәрефләре | 1 | 20.10 | | |
| 9 | Сүзләрне иҗекләргә бүлү, сүз басымын билгеләү. Басымлы һәм басымсыз сузыкларны аеру. [р] авазы. Р,р хәрефләре кергән сүзләрне уку. Сүз кисәге буларак иҗек турында белешмә. | 1 | 27.10 | | |
| 10 | Сүз һәм җөмләне аеру. Сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне һәм кыска текстларны аңлап уку. [й], [н] авазлары, Й,й ; ң хәрефләре | 1 | 10.11 | | |
| 11 | Калын һәм нечкә әйтелешле сүзләрдә сузык авазларның роле. Я,я; Ю, ю; Е,е хәрефләре, аларның аваз мәгънәләре. Е-ё, ю, я хәрефләренең кулланылышы. | 1 | 17.11 | | |
| 12 | Сюжетлы рәсемнәр, үзеңнең уеннарың, күзәтүләрең буенча хикәяләү характерындагы зур булмаган текстлар төзү. Яңгырау һәм саңгырау тартык авазларны аеру. [д], [т] авазлары, Д,д; Т,т хәрефләре. | 1 | 24.11 | | |
| 13 | Әдәби әйтелеш нормаларын саклап, иҗекләрне һәм сүзләрне тиешле тизлек белән уку. [з], [с] авазлары, З,з; С,с хәрефләре. | 1 | 1.12 | | |
| 14 | Бер яки берничә авазы белән аерыла торган сүзләрне чагыштыру. [г] ,[гъ] [к],[къ] авазлары, Г,г ; К,к хәрефләре. | 1 | 8.12 | | |
| 15 | Укыганда орфоэпия нормаларын төгәл саклау, дөрес тавыш төсмерләре белән укырга өйрәтү. [W],[в],[ф] авазлары. В,в; Ф,ф хәрефләре. | 1 | 15.12 | | |
| 16 | [б] [п] авазлары. Б,б ; П,п хәрефләре | 1 | 22.12 | | |
| 17 | Зур булмаган текстны һәм шигырьләрнең эчтәлеген аңлап, сәнгатьле итеп уку . [ж] , [ш] авазлары, Ж,ж ; Ш,ш | 1 | 12.01 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | хәрефләре | | | | |
| 18 | Тиз һәм йөгерек уку. [ж] , [ч] авазлары, Җ,ж ;Ч,ч хәрефләре. | 1 | 19.01 | | |
| 19 | [х], [һ] авазлары. Х,х; Һ,һ хәрефләре. | 1 | 26.01 | | |
| 20 | Гади җөмлә ахырындагы тыныш билгеләренә игътибар итеп, тиңдәш кисәкләрне, эндәш сүзләрне тиешле интонация һәм пауза белән уку. Е,е хәрефләре. [щ] , . [ц] авазлары, Щ,щ ; Ц,ц хәрефләре. | 1 | 2.02 | | |
| 21 | Укылган текстның эчтәлеген аңлау. Нечкәлек(ь) , калынлык (ъ) билгеләренең кулланылышы | 1 | 16.02 | | |
| 22 | Дәреслек белән танышу.Сәяхәткә чыгу.<br>Халык авыз иҗаты турында гомуми күзаллау. | 1 | 2.03 | | |
| 23 | Кайтаваз мәгарәсе. Рифма белән танышу: аны сиземли, таба, куллана белергә күнектерү | 1 | 9.03 | | |
| 24 | Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып танып белү. Ләбиб Лерон шигырьләрендә кызыклы вакыйгалар | 1 | 16.03 | | |
| 25 | Аю өне янында. Әйләнмәле һәм<br>чылбыр әкиятләре. | 1 | 23.03 | | |
| 26 | Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Чәчәкле аланда | 1 | 6.04 | | |
| 27 | Тормыш-көнкүреш әкиятләре, аларның килеп чыгышы. Э.Шәрифуллинаның “Бәйрәм ашы кара-каршы”әкиятендә дуслык темасы | 1 | 13.04 | | |
| 28 | Кеше һәм табигать бергәлеге.<br>Х.Халиков шигырьләрендә ярдәмләшү темасы | 1 | 20.04 | | |
| 29 | Геройның эчке дөньясын аның әйләнә-тирә дөньяны танып белүе аша күрсәтү. Р.Миңнуллин, Ш.Галиев шигырьләре | 1 | 27.04 | | |
| 30 | Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Р.Миңнуллинның “Шүрәлесез урман”, Х.Халиковның “Әгәр күрә белсәгез” шигырьләре | 1 | 4.05 | | |
| 31 | Арадаш аттестация кысаларында йомгаклау эше. | 1 | 11.05 | | |
| 32 | Йомгаклау эшенә анализ. Р.Вәлиеваның “Кыңгырау чәчәк”. Әкиятләрнең тәрбияви роле. | 1 | 18.05 | | |
| 33 | Әдәби әсәрләрнең башка сәнгать әсәрләре белән бәйләнеше. | 1 | 25.05 | | |

## Календарь-тематик планлаштыру

**УМК** “Перспектив башлангыч мәктәп” Әдәби уку. Г.М. Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина, Ә.Г.Мөхәммәтҗанова, Ф.Ф.Хәсәнова. Татар башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 2 нче сыйныфы өчен дәреслек ике кисәктә һәм хрестоматия. Казан, “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты, 2012.

| | **Дәрес темасы** | **Сәг. саны** | **Үткәрү вакыты** | | **Искәрмә** |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | **План** | **Факт** | |
| | Сәнгатьнең бер төре буларак китап. Китап элементлары: | 1 | 02.09 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | эчтәлеге яки бүлекләр исемлеге, титул бите, аннотация, иллюстрацияләр. Әкиятләр турында гомуми күзаллау булдыру. Автор әкиятләре. Автор теленең кабатланмас матурлыгы. Г.Тукай “Кәҗә белән Сарык “ әкияте.Әкиятнең жанр үзенчәлеге. | | | | |
| | Автор һәм халык әкиятләрендә сюжет-композиция охшашлыгы, яңа мәгънәви төсмерләр бирү. Г.Тукай әсәрләрендә халык авыз иҗатының чагылышы. “Эш беткәч, уйнарга ярый”, “Сабыйга”. Йолдыз “Кояшка җавап” | 1 | 9.09 | | |
| | Хайваннар турында татар халык әкиятләрендә төп герой, аның характеры. “Батыр этәч”, «Кәҗә белән бүре?» татар халык әкиятләрен уку. Йорт хайваннары турындагы халык әкиятләре. Татар халкының хайваннар турындагы әкиятләрендә төп герой, аның характеры. “Әтәч патша” әкияте | 1 | 16.09 | | |
| | Кыргый җәнлекләр турындагы әкиятләр."Бүдәнә белән төлке”. .”Аю белән төлке” әкиятен уку. Борынгы әкиятләр Россия халыклары әкиятләре. Җәнлекләр турында гуцул халык әкияте “Хәйләкәр керпе” | 1 | 23.09 | | |
| | Риваять турында гомуми күзаллау. Аз булса да үз акылың булсын. Мәҗит Гафури. «Тавык белән үрдәк» мәсәле, “Тавык нигә суда йөзә алмый?” риваяте Тылсымлы әкиятләр, аларның төзелеше. Җирдәге һәм тылсымлы дөньяны чагыштыру . Тылсым дөньясы, булышчылар, тылсымлы предметлар, тылсымлы саннар (3, 7, 13, 40). “Гөлчәчәк” әкияте | 1 | 30.09 | | |
| | Халык авыз иҗаты. Мәкальләр. Дуслык турында мәкальләр. Г.Юнысова “Керпе кайгысы” Борынгы дөньяның тылсымлы әкиятләрдә чагылышы. Тылсымлы дөньядагы предметлар, булышчылар.”Өч кыз” әкияте өстендә эш. А.Алиш “Бикбатыр белән Биккуркак”. | 1 | 07.10 | | |
| | Автор әкиятләре белән борынгы әкиятләр арасындагы идея уртаклыгы. Ш.Галиев “Җизни әкияте”, Юмористик әсәрләр. Ш.Галиев әсәрләрендә мәзәк мәсьәләләр. “Ник соң итек җитмәде”. “Котбетдин мәргән”(мәзәк маҗара). Юмористик әсәрләр. Н. Исәнбәт «Мияубикә төше» | 1 | 14.10 | | |
| | Уйдырма әкиятләр.Н.Исәнбәт “Мырауҗан агай хәйләсе”. Әкияти вакыйгалар. А.Нигъмәтуллин. «Автопортрет». Һ.Такташ “Тәүфыйклы песи” Бөҗәкләр турындагы шигъри әсәрләр.З.Мансур ”Кырмыска һәм малай” Р.Миңнуллин “Черкиләр җыры” | 1 | 21.10 | | |
| | Автор һәм халык әкиятләрендә охшашлык. Тылсымлы шигъри әкиятләр , аларда халык әкиятләре белән сюжет бәйләнеше, композиция үзенчәлеге. Г.Вәлиева “ Борынгы әкият”, “Су әкияте”, «Каен елый».”Музей йортына сәяхәт” Әсәр геройларына карата үз фикереңне белдерү. Йолдыз “Белмим”. Ф.Яруллин “Ике кеше”. Л.Лерон «Сараватта кем ята?» . Р.Вәлиева “Замана баласы”. | 1 | 11.11 | | |
| | Әсәр исеменең төп мәгънә, эчтәлек белән туры килүе. Г.Морат “Татар космонавты” Эш эшкә өйрәтә. | 1 | 18.11 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Ф.Яруллин “Эшнең аның берние юк”. Л.Лерон “Үскәч” Ж.Дәрзаман “Солдат булдым”. | | | | |
| | Дөньяның күп төсле, формаларның күп төрле булуы.”Музей йортына сәяхәт”. Г.Тукай “Буран”. В.Нуриев “Җәйге кар”. Хоккулар. Кыска шигырьләр. Н.Ахунова “хоккулар”ы | 1 | 25.11 | | |
| | Лирик герой. Кыска шигырьләр. ”Музей йортына сәяхәт”. Әдәби әсәрләрнең башка сәнгать әсәрләре белән бәйләнеше. Р.Миңнуллин “Яз керде өебезгә”.Р.Вәлиева “Умырзаялар”. Р. Фәйзуллин «Кышын», “Язгы кәеф” | 1 | 2.12 | | |
| | Әкият һәм чынбарлык бергәлеге. Э.Шәрифуллина “Алтын балык”. | 1 | 09.12 | | |
| | Геройның эчке дөньясын аның әйләнә-тирә дөньяны танып белүе аша күрсәтү. И.Лерон “И ямьле дә соң дөнья!” ”Музей йортына сәяхәт”. Әдәби әсәрләрнең башка сәнгать әсәрләре белән бәйләнеше. Каюм Насыйри. «Хикәят». | 1 | 11.12 | | |
| | Күзәтә белгән кеше- бәхетле кеше. И.Туктар “Урман букеты”. “Серле ачкыч” мәктәп клубына хат язу. Р.Миңнуллин “Чыршы әйләнәсендә”. Э.Шәрифуллина “Яшел чыршы, яшь чыршы” | 1 | 16.12 | | |
| | Күзәтү ноктасы. С.Урайский, Р.Харис “Төсле рәсем”. Дөньяны танып белүнең яңа ысуллары. Ш.Галиев “Яңа фотоаппарат”. Ф.Садриев “Тәҗрибә” | 1 | 23.12 | | |
| | Хыялда тудырган дөнья. Р.Миңнуллин “Рәсем”. Р.Сарби “”Рәсем”. Р.Мингалим “Кызык рәсем” ”Музей йортына сәяхәт”. Р.Миңнуллин “Ак кыш”. | 1 | 13.01 | | |
| | Г.Юнысова “Күзләр”.Г.Гыйльманов “Күнел күзе”. Н.Арсланов “Сезнеке”. | 1 | 20.01 | | |
| | Чагыштыру, контраст, җанландыру. Р.Миңнуллин “Ай нәрсәгә охшаган”,Р.Миңнуллин “Беркемгә дә охшамаган” Дөньяга төрлечә караш. М.Әгъләмов “Ямь-яшел”. М.Шабаев “Идел суы”. | 1 | 27.01 | | |
| | Дөнья белән танышуны дәвам итү(су өслегe) Н.Мадьяров”Үз шәүләсен куркыткан”. З.Минһаҗева “Су иясе”. Кеше һәм табигать бергәлеге. Ф Садриев “Боз өстендә” | 1 | 03.02 | | |
| | Бер тамчы суга дөнья ничек сыйган? Г.Шаһи “Тамчы”. Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып танып белү. Ф.Зыятдинов “Тәрәзәләр”., Р.Фәйзуллин “Бинокль”., | 1 | 10.02 | | |
| | Син-миңа, мин синә карыйм. Г.Тукай “Карлыгач”, Р.Хафизова “Күңел күзе” Алар-безгә, без-аларга карыйбыз., Ж.Дәрзаман “Балык тотты”, Б.Рәхмәт “Гөлйөзем белән чебен” | 1 | 17.02 | | |
| | Ә.Гаффар «Әни йөрәге». Ш.Галиев “Һәркем әйтә дөресен” | 1 | 24.02 | | |
| | Әсәр геройларының тирә-якка, дөньяга карашларын чагыштырып карау. Ф.Зыятдинов “Карга белән Шөпшә”. Ш.Галиев “Сизгер суган” ”Музей йортына сәяхәт”, Ж.Дәрзаман “Күбәләк кар”, А.Нигъмәтуллин “Кар”. Г.Ибраһимов “Кар ява” | 1 | 02.03 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Бер предметка төрлечә караш. Р.Миңнуллин “Кем соң минем Әби?”, Йолдыз “Сөенеч”, Л. Шәех «Картлар нигә шатлар?» Г. Тукай «Мактанчык куян» | 1 | 9.03 | | |
| | Кечкенә дә төш кенә. Ә. Моталлапов “Кечкенә дә төш кенә”, Йолдыз “Бабай белән малай”. ”Музей йортына сәяхәт”.Р.Миңнуллин “Йорт агачлары” | 1 | 16.03 | | |
| | “Серле ачкыч” мәктәп клубы утырышы. Г.Тукай “Бу кайчак була?”, Р.Корбан “Ел фасыллары”, Г.Афзал “Беренче кар”, Л.Лерон “Яз” | 1 | 13.04 | | |
| | Үзеңнең һәм авторның геройга мөнәсәбәтен ачыклау. Р.Миңнуллин “Төрле кешеләр була”,”Юкка малай булганмын”. Р.Вәлиева “Рәхәт безнең Акбайга” Хикәя герое. Р.Вәлиева “Шатлык кызы”. Г.Мөхәммәтшин “Күбәләк”. М.Җәлил “Бер шигырь” «Себерке әкияте» шигырьләре | 1 | 20.04 | | |
| | Яңалыклар ничек тарала? Р.Миңнуллин “Малайлар сөйләшә”. Г.Морат “Мультфильмнар карыйбыз”Газета-журналларның ни өчен вакытлы матбугат дип аталуын,яңалык белән гайбәт арасындагы аерманы аера белү. Балалар журналлары. Балалар газеталары. Журналларда һәм газеталарда ориентлаша белү. “Серле ачкыч” мәктәп клубы утырышы. Ш.Галиев “Тынлык”. Йолдыз “Хыял”. | 1 | 27.04 | | |
| | Шагыйрь өчен табигать-серле һәм җанлы дөнья.Г.Хәсәнов “Имән каргасы”. Р.Вәлиева «Урманда бәйрәм булган» Якты тәрәзә каршында. ”Музей йорты”на сәяхәт. | 1 | 4.05 | | |
| | Кышкы урман матурлыгы. Ә.Еники “Кышкы урман”, Йолдыз “Бәхетле агач”.И.Туктар “Кышкы урман”Якты күл сагышы. Ф.Сафин”Якты күл сагышы” М.Фәйзуллина “Агачлар да күлмәк алыштыра”. Р.Газизов “Ял көнендә”. Йолдыз “Салават күпере”. Сөләйман “Тау белән сөйләшү”. | 1 | 11.05 | | |
| | **Арадаш аттестация (Еллык билге кую/Текст белән эш)** | 1 | 19.05 | | |
| | Хаталар өстендә эш. Көлке ничек туа? Л.Лерон “Тишек хәтер”. Шаяртуның да бер төп мәгънәсе була. М.Галиев “Көзге каршында”, М.Шабаев “Зәңгәр песи” ,“Умырзаялар”, Р.Вәлиева “Ак песи”, В.Нуриев “Шүрәле” | 1 | 25.05 | | |
| | Гаҗәпнең дә гаҗәбе, мәзәкнең дә мәзәге.Э.Шәрифуллина “Оттырды”, Л.Лерон “Гаҗәп хәлләр”.<br>Йолдыз “Ялган хакында чын” Искитмәле тамашалар.М.Галиев “Тамаша”, М.Мөхәммәтшин ”Көчле булсам”. Ф.Яруллин “Композитор чыпчыклар” . Л.Лерон «Камилнең көләсе килә»“ Серле ачкыч” мәктәп клубына хат. Р.Гаташ «Зәңгәр ил – балачак иле»“Сабантуй”газетасында кунакта. Җәйге биремнәр. Уку елын йомгаклау. Йолдыз “Матурлык”, “Манзара” | 1 | 25.05 | | |

**Календарь-тематик планлаштыру**

